# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге составына керүче Усали торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 10 «20» октябрь, 2023 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Усали торак пунктында 2023нче елның «20» октябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Усали торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2024 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Агач кисү (махсус машина яллау, килешү буенча эш өчен түләү);
- Комсомол урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү):
- Беренче Май урамы һәм Татарстан урамы буенча вак таш белән капланган юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү);
- Усали торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Усали торак пунктында лампалар, яктырту җиһазларын кайтарту, договор буенча хезмәт күрсәтүгә түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 302 кеше кертелгән; гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 190 кеше, 63 % тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 190 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Усали торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Усали торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге Усали торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2023 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Агач кисү (махсус машина яллау, килешү буенча эш өчен түләү);

- Комсомол урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү):

- Беренче Май урамы һәм Татарстан урамы буенча вак таш белән капланган юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү);

- Усали торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

- Усали торак пунктында лампалар, яктырту җиһазларын кайтарту, договор буенча хезмәт күрсәтүгә түләү;

3. Әлеге карарны Усали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А.И.Зиатдинов